РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ**
22 марта 2017 г. № 12

**КАРАР**
2017 елның 22 марты № 12

**Түбән Кама шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2014 елның 20 ноябрендәге 30нчы карарына үзгәрешләр кертү турында**
(2015 елның 15 июнендәге 22, 2015 елның 23 октябрендәге 16, 2016 елның 13 сентябрендәге 29, 2016 елның 8 ноябрендәге 32 номерлы карарлары редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 30 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына (алга таба – «карар») түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 1.12 пункты белән тулыландырырга:

«1.12. Автомәктәпләр полигоннары һәм автодромнары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,2 процент".

Карарның 1 өлешендәге 1.12 пунктының гамәлдә булуы 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

1.2. Карарның 1 өлешендәге 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Физик һәм юридик затларга, индивидуаль торак төзелешеннән тыш, аларны гамәлгә ашыру шартларында беркетелгән җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент".

Карарның 1.2.1., 1.2.2. пунктлары үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. Карарның 4нче өлешен киләсе эчтәлектәге 4.3 пункт белән тулыландырырга.: «4.3. салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

индустриаль (сәнәгать) парклар һәм сәнәгать технопарклары".

1.4. Карарның 5 өлешен түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга: «Карарның 4.3 пунктында каралган очраклардан тыш.».

2. Әлеге карарның 1.2, 1.3, 1.4 пунктлары рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин